ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.03.2024 Балык Бистәсе штп. № 71пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының эвакуация комиссиясен төзү турында» 06.09.2023 №309пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының эвакуация комиссиясен төзү турында» 06.09.2023 №309пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның преамбуласында һәм Нигезләмәнең 1.1 пунктында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү тәртибе турында" 2004 елның 22 июнендәге 303 номерлы карары белән" дигән сүзләрне "Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү тәртибе турында" 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы карары белән" дигән сүзләр белән алыштырырга, "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Республика эвакуация комиссиясе һәм аның составы турында Нигезләмәне раслау хакында" 2006 елның 26 июнендәге 323 номерлы карары" сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы эвакуация комиссиясен төзү турында" 2020 елның 24 июлендәге 620 номерлы карары белән" дигән сүзләр белән алыштырырга;

1 нче кушымтаның 2.3 пунктындагы а пунктчасының 2 нче абзацында, 3 нче кушымтаның 1 нче пунктындагы 4 нче абзацында, 3 нче кушымтаның 2 нче пунктындагы 7 нче абзацында «ТР Балык Бистәсе муниципаль районында эвакуацияләнүче һәм урнаштырылучы халыкны кабул итү, урнаштыру һәм беренче чиратта яшәүне тәэмин итү планы» дигән сүзләрне "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының эвакуацияләү чаралары планы" дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д. А. Сатдинов